ГЛАВА ТАШКИЧУЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.21А, д.Малые Уруссу, 423959

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАШКИЧҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 21А йорт, Рече Урыссу авылы., 423959

Тел.:(85593) 4-23-10, факс:4-23-40, e-mail: Tash.UTz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«08» ноябрь 2024 ел № 14

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге составына керүче Биектау торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 26, 92 маддәләре нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 20 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Биектау бистәсе, Тынычлык урамы, 26 йорт адресы буенча урнашкан бина янында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Биектау торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Биектау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 700 (җиде йөз) сум күләмендә билгеләргә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүдән үзара салым кертүгә ризамы?:

-Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегенең Биектау торак пунктындагы традицион күмү урыннарын төзекләндерү (зиратка капкалар әзерләү, урнаштыру, материаллар алу, килешү буенча эшләр өчен түләү, транспорт чыгымнары).

«РИЗА» «КАРШЫ»

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитетына Биектау торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru.), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru / электрон адресы буенча кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.К.Вәлиев

1.